| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 Казан ш. № 329-21/тко-2021

«Санитарно-экологические системы - Регион» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2022 елга чик тарифлар билгеләү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә «Санитарно-экологические системы - Регион» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календарь буенча бүленгән чик тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.
3. «Санитарно-экологические системы - Регион» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.11.2021 № 329-21/тко-2021
карарына кушымта

2022 елга «Санитарно-экологические системы - Регион» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|
| | | 2022 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Апас муниципаль районы | | |
| 1 | «Санитарно-экологические системы - Регион» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 125,85 | 137,43 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге